Ачык дәрес планы.

Максат: 1. Шарт фигыль, аның мәгънәсе, төрләнеше һәм җөмләдә кулланылышын өйрәтү.
2. Шарт фигыльне дөрес язу күнекмәләрен булдыру; сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтү.
3. Татар халык авыз иҗаты әсәре булган сынамышлар аркылы балаларның игътибарын тирә-як мохитка, табигать күренешләренә юнәлтү, әхлак тәрбиясен бирү.
Дәрес тибы: ныгыту.
Кулланылган технологияләр: компьютер, шәхескә якын килү, эшчәнлек.
Кулланылган метод һәм алымнар: проблемалы сорау кую, өлешчә эзләнү, әңгәмә, төркемләп, парлап эш, индивидуаль эш.
Җиһазлау: “Шарт фигыль” темасына презентация, шәхси һәм төркемләп эш өчен карточкалар.
Кулланылган дәреслек һәм өстәмә әдәбият: 8 нче класс татар теле, “Татар халык авыз иҗаты” җыентыгы(сынамышлар).

Дәрес барышы.

I.**Оештыру өлеше**.
- Исәнмесез, укучылар. Хәерле иртә!
Кәефләрегез ничек соң?
Һәрберебезгә бу иртәдә хәерле көннәр телик. Менә шушы изге теләк белән дәресебезне башлыйбыз.

Фонетик зарядка

Ба ба ба Бу безнең бабай.
Би би би Бу безнең әби
Га га га Туганнан туган бала
Ге ге ге Бу чибәр егет
Та та та Кайната тегә чабата
Ки ки ки Килә кодагый
Ни ни ни Бу минем әни

Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду:
Килсә, яуса,ялкауланса, теләсә, белсә, тыңлый,укыса
Сораулар:
1. Әйткән сүзләр нинди сүз төркеменә керә?(Фигыль)
2. Нинди фигыль төрләре була?

1слайд- Фигыль төрләре.
3. Аудированиядә күбрәк нинди фигыль төрләре бирелгән иде?
4. Нинди фигыль шарт фигыль дип атала?
5. Ул башка фигыльләрдән ничек аерыла, ничек ясала?
(-СА кушымчасы белән аерыла)
-Кем әйтә, бүгенге дәреснең темасы нинди?(*Шарт фигыль*).
Теперь послушайте меня:
Кар калын булса, ашлык уңар.
Кар калын булмаса, ашлык уңмас.
что изменилось?
(Димәк, ШАРТ фигыль боерык фигыльгә + -СА, -СӘ , -МАСА, -МӘСӘ кушымчалары ярдәмендә кушылып ясала).

3 слайд

Шарт фигыль турында төшенчәне кабатлап үтик.
4 слайд
Димәк, шарт фигыльнең юклык формасы ничек ясала? (-ма/-мә кушымчасы белән ясала).
- Мисаллар белән ныгытыйк. Мин фигыльләрне барлыкта, ә сез юклыкта әйтегез.Челтәрләп әйтәбез.
укыса-
белсә-
алса-
килсә-
ялкауланса
әзерләсә
барса
өлгерсә
булса
теләсә
ярдәм итсә-
алып барса-
5 слайд Шарт фигыльнең зат- сан кушымчалары хикәя фигыльнең кайсы заман формасы кушымчалары белән туры килә?(укучылар җавабы)
(*Димәк, шарт фигыльнең зат- сан төрләнеше билгеле үткән заман хикәя фигыльнең төрләнеше белән туры килә).* Сезгә моны истә калдыру уңайлы дип уйлыйм.
Слайд 6.Бирелгән җөмләләрне укып үтик.
1. Тотынсаң, синнән дә менә дигән мастер чыгачак бит.(Г.Әбсәлмов)

2.Ялганчы икәнлегеңне сизсәләр, әлбәттә, рәхмәт әйтмәсләр.
3. Көз озын килсә, яз соң килер.(сынамыш)
4 Кар калын булса, ашлык уңар .(сынамыш)
5. Кыш кар күп булса,җәй яңгырлы булыр .(сынамыш)
6.Әгәр өлгерсәк,бүген сезгә кереп чыгарбыз.
7.Әгәр сез театрга барсагыз һәм безне дә үзегез белән алсагыз, без бик шат булыр идек.
8. Ишеткән булса, миңа да әйтер иде ул.(Ш.Камал)
9. Белмәсәгез, тик торыгыз(Г.Ибраһимов)
10.Минемчә, кеше ялкауланмаса, хезмәтне яратса, һәр эштән кызык табып яши
.

Бүгенге дәрестә без сезнең белән 3 төркемдә эшләрбез. Һәркем үз эшенә үзбәя куеп барыр.
6 слайд.Җөмләләр бирелә.
Бирелгән сүзләр арасыннан
1 нче төркем хәзерге заман хикәя фигыльләрне сайлап яза.
2 нче төркем киләчәк заман хикәя фигыльләрне сайлап яза.
3 нче төркем шарт фигыльләрне сайлап яза.
Төрле төстәге фломастер куллана аласыз
7 слайд. Дәреслеге экраннан тикшерелә Үзбәя куегыз.
Шарт фигыльләрнең затын һәм санын билгеләгез

Китапларда эшләп алыйк әле.77 нче бит, 9 нчы күнегү.
Биремне укы.
Бу җөмләләрдә нинди фигыльләр еш очрый? *Шарт фигыльләр. Тәрҗемә итегез.*
Кеше ярлы булмас өчен нинди булырга тиеш?
Терәк сүзләр һәм сүзтезмәләр кулланып үз фикерегезне әйтегез:
Терәк сүзләр: Иртә торырга, изге эшләр эшләргә, ярдәм итәргә, алдагы көн турында уйламаска,юмарт булырга,компьютерда озак уйнарга, күп йокларга,вакытны зая уздырырга,гел телефоннан сөйләшергә, күп укырга,кеше хәленә керергә,күп эшләргә, ялкауланмаска, тырыш булырга
Символлар белән берничә рәсем төшерегез. Ярлы кеше булмас өчен реклама ясарга.
Әйе, дөрес, укучылар кеше ялкау булмас өчен тырыш булырга тиеш.
Без үткән эшне төрле фломастерлар ярдәмендә язган идек.

Төс – реклама образын тудыруда иң көчле элементларның берсе. Психологлар фикеренчә, реклама сурәтенең төсе укучының үзаңына нык тәэсир итә. Кулланучы төс аша товар турында төрле мәгълүмат ала.
Рекламада кайсы төскә күбрәк игътибар итәләр соң?
Ак төс – чисталыкны символлаштыра, шул ук вакытта ул салкын һаваны, бозны хәтерләтә.
Кызыл төстә булса, ул энергияне, агрессивлыкны күздә тота.
Кызгылт сары төстә булса, оптимизм өсти, сәламәтлек, гармонияне, яшьлекне символлаштыра.
Сары төс төстә булса, кояш төсе, аралашуга чакыра.
Яшел төстә булса, яңаруны символлаштыра, тыныч ландыра.
Америкада бу төс – байлыкны, Һиндстанда – ышаныч-өмет хисләрен, Кытайда – зиннәтле тормышны символлаштыра.
Күк төсе шулай ук хисләргә, фантазиягә мөрәҗәгать итә. Ул укучыларда уңай эмоцияләр тудыруга хезмәт итә – зәңгәр күккә, биеклеккә омтылу, яңа илләр күрү теләкләрен уята.
Куе зәңгәр төс – бөтенлек символы. Ул эшкә өнди, үзенең белән рекламага энергия алып килә. Бу энергия беркайчан да агрессив булмый. "Эшлекле" төс.
Шәмәхә төс укучының эчке дөньясына мөрәҗәгать итә, проблемалардан, тормыш мәшәкатьләреннән арынырга булыша.
Психологлар фикеренчә, бу төс ми эчәнлеген яхшырта, концентрациягә ярдәм итә. Укучы белән реклама бирүче арасында эшлекле мөнәсәбәтләр тудырырга булыша.
Эшлекле төс нинди төс булып чыкты?(Күк, куе зәңгәр, шәмәхә төс

Укучыларга индивидуаль эш.

1.Юеш кием белән ..., суык тия.
1. *Телевизорны күп ... , баш авырта.*
2. *Тырышып..., күп беләсең.*
3. *Йокыдан вакытында ..., мәктәпкә соңга калмыйсың.*
4. *Иртә... , аш пешә; соңга ..., бит пешә.*

Кирәкле сүзләр:торсаң, карасаң, укысаң, калсаң,йөрсәң
Преобразуйте слова, написанные в конце строк, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста.
5. 1. Укытучыны ____яхшы эш түгел. (**тыңлама**)
2. Иртән зарядка ___ сәламәтлек өчен файдалы. (**Яса**)
3. Эссе көндә салкын су ___ рәхәт, ләкин ярамый. (**Эч**)

4.Укырга _____,мин бу журналны сиңа берничә көнгә биреп торам. (**телә**)

Җаваплары

Укытучыны тыңламасаң яхшы эш түгел.

Иртән зарядка ясасаң сәламәтлек өчен файдалы.

Эссе көндә салкын су эчсәң рәхәт, ләкин ярамый.

Укырга теләсәң, мин бу журналны сиңа берничә көнгә биреп торам.

Тактада эшләгәндә **диалогта төшеп калган репликаларны өстәгез, үзара сөйләшегез**.

1.- ... ?
- Әйе, “ике”ле алсам, кәефем китә.
- ... ?

2. – Дима, безгә киләсеңме?
- Әни рөхсәт итсә, бүген кич киләм.
- Ә көндез нәрсә эшлисең?
-.....

Карточкалар таратыла(индивидуаль эш)

Нокталар урынына тиешле фигыльләрне куеп языгыз

...сәм укырмын
...сәң күрерсең
...сак керербез
...масагыз утыртырсыз

Җөмләләрне язып бетер.

Мәктәптән иртә кайтсам,....
Дәресләрне әзерләсәң, ...
Күп укысаң,....

..., мин дә аңа булышыр идем.
..., мин аңа күлмәген үзем үтүкләп бирәм.
..., аларга салкын тияргә мөмкин.
..., син аны сатып алырга тырыш.

Как скажите о том, что:

1. Если бы ты делал рекламу , то какие цвета бы ты взял ?
2. Если бы у меня были деньги, я бы путешествовал по всему миру.
3. Если будешь трудолюбивым, многого добьешься

Дәресне йомгаклау

Укучылар, без сезнең белән бүген дәрестә нинди фигыльне кабатладык?
-Нинди кушымчалар ялгана?

-Нинди сорауга җавап бирә?

Рефлекция. “Шарт фигыль” темасы буенча алган белемнәр искә төшерелеп кабатлана. (10 нчы слайд.)

Йомгак.

- Укучылар, онытмагыз: билгеле бер шартлар үтәлсә генә, тормышыбыз матур, киләчәгебез якты булыр. Шарт фигыль шуңа өйрәтә. Сез барыгыз да, Тамчыкай кебек - табигать балалары. Димәк, табигать- уртак йортыбыз. Үзебезнең изге эшләребез белән саклыйк аны, яклыйк аны.

VI. Билге кую.

Мәңгелеккә дәшә сыман
Безгә Риза Фәхретдин.
Яшик әдәп, әхлак белән,
Көнебез үтсен имин.

Сынамышлар: 1.Кояш кич кызарып баеса, көн аяз булыр. 2. Карлыгачларның түбән очуы яңгырга. 3.Салават күперенең ике башы да суга төшсә, яңгыр кабат явар. 4. Явым алдыннан томан күтәрелә. 5. Күк болытлар арасында ак болыт булса, боз явар.6. Көнчыгыштан чыккан җил – буранга.

Кыш кар күп булса,җәй яңгырлы булыр.
Көз озын килсә, яз соң килер.
Мәче су эчсә, яңгыр булыр.
Кар калын булса, ашлык уңар.

Талантныңы бер олеше тумыштан,
Тыныз олеше тырышлыктан.

Фигыль төркемчәләре

- Хикәя
- Боерык
- Шарт
- Инфинитив
- Исем
- Сыйфат
- Хәл

Глагол в условном наклонении (шарт фигыль)

обозначает действие, которое является условием для совершения другого действия, и отвечает на вопросы Нишләсә? Нишләмәсә? Условное наклонение глагола образуется от основы глагола при помощи аффикса *-са-сә,* отрицательное форма *–ма-мә*.

Например: ***Кил - килсә (если придет). Укыса – если прочитает. Килмәсә(если не придет). Укымаса (если не прочитает)***

Шарт фигыль

барлыкта

-са/-сә

Мин эшләсәм
Син эшләсәң
Ул эшләсә
Без эшләсәк
Сез эшләсәгез
Алар эшләсәләр

юклыкта

-ма/-мә

Мин эшләмәсәм
Син эшләмәсәң
Ул эшләмәсә
Без эшләмәсәк
Сез эшләмәсәгез
Алар эшләмәсәләр

Шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнеше

Барлык формасы	Юклык формасы
Берлек сан	**Берлек сан**
1зат – укысам	1зат – укымасам
2зат – укысаң	2зат – укымасаң
3зат – укыса	3зат – укымаса
Күплек сан	**Күплек сан**
1зат – укысак	1зат – укымасак
2зат – укысагыз	2зат – укымасагыз
3зат – укысалар	3зат – укымасалар

Җөмләләр:

1. Тотынсаң, синнән дә менә дигән мастер чыгачак бит. (Г.Әбсәләмов)
2. Ялганчы икәнлегеңне сизсәләр, әлбәттә, рәхмәт әйтмәсләр.
3. Көз озын килсә, яз соң килер. (сынамыш)
4. Кар калын булса, ашлык уңар. (сынамыш)
5. Кыш кар күп булса,җәй яңгырлы булыр. (сынамыш)
6. Әгәр өлгерсәк, бүген сезгә кереп чыгарбыз.
7. Әгәр сез театрга барсагыз һәм безне дә үзегез белән алсагыз, без бик шат булыр идек.
8. Ишеткән булса, миңа да әйтер иде ул. (Ш. Камал)
9. Белмәсәгез, тик торыгыз. (Г. Ибраһимов)
10. Минемчә, кеше ялкауланмаса, хезмәтне яратса, һәр эштән кызык табып яши.

Дөрес җаваплар:

Киләчәк заман хикәя фигыльләр: чыгачак, бармабыз,кереп чыгарбыз, булыр идек, әйтер иде,килер, булыр, уңар

Хәзерге заман хикәя фигыльләр: табып яши

Шарт фигыльләр: *тотынсаң, сизсәләр, әйтмәсләр , өлгерсәк, барсагыз, алсагыз, булса,килсә, белмәсәгез, ялкауланмаса, яратса*

Шарт фигыльнең затын, санын билгеләгез

1. *Тотынсаң*, синнән дә менә дигән мастер чыгачак бит. (Г.Әбсәлмов)
2. Ялганчы икәнлегеңне *сизсәләр*, әлбәттә, рәхмәт *әйтмәсләр.*
3. Көз озын *килсә*, яз соң килер. (сынамыш)
4. Кар калын *булса,* ашлык уңар. (сынамыш)
5. Кыш кар күп *булса*,җәй яңгырлы булыр. (сынамыш)
6. Әгәр *өлгерсәк,* бүген сезгә кереп чыгарбыз.
7. Әгәр сез театрга *барсагыз* һәм безне дә үзегез белән *алсагыз*, без бик шат булыр идек.
8. Ишеткән *булса*, миңа да әйтер иде ул. (Ш. Камал)
9. *Белмәсәгез*, тик торыгыз. (Г. Ибраһимов)
10. Минемчә, кеше *ялкауланмаса*, хезмәтне *яратса*, һәр эштән кызык табып яши.

Рекламада кайсы төскә күбрәк игътибар итәләр соң?

Ак төс – чисталыкны символлаштыра, шул ук вакытта ул салкын һаваны, бозны хәтерләтә.
Кызыл төстә булса, ул энергияне, агрессивлыкны күздә тота.
Кызгылт сары төстә булса, оптимизм өсти, сәламәтлек, гармонияне, яшьлекне символлаштыра.
Сары төс төстә булса, кояш төсе, аралашуга чакыра.
Яшел төстә булса, яңаруны символлаштыра, тынычландыра.
Күк төсе шулай ук хисләргә, фантазиягә мөрәҗәгать итә. Ул укучыларда уңай эмоцияләр тудыруга хезмәт итә – зәңгәр күккә, биеклеккә омтылу уята.
Куе зәңгәр төс – бөтенлек символы. Ул эшкә өнди, үзенең белән рекламага энергия алып килә. Бу энергия беркайчан да агрессив булмый. "Эшлекле" төс.
Шәмәхә төс укучының эчке дөньясына мөрәҗәгать итә, проблемалардан арынырга булыша.Укучы белән реклама бирүче арасында эшлекле мөнәсәбәтләр тудырырга булыша.

Индивидуаль эш

Җөмләләрне язып бетер

1. Мәктәптән иртә кайтсам, ...
2. Дәресләрне әзерләсәң, ...
3. Күп укысың, ...
4. ..., мин дә аңа булышыр идем.
5. ... ,ул да минем белән сөйләшер иде.

Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста.

1. Укытучыны ____яхшы эш түгел. (**тыңлама**)
2. Иртән зарядка ___ сәламәтлек өчен файдалы. (**Яса**)
3. Эссе көндә салкын су ___ рәхәт, ләкин ярамый. (**Эч**)
4. Укырга _____,мин бу журналны сиңа берничә көнгә бирер торам. (**телә**)

Җаваплары

1. Укытучыны **тыңламасаң** яхшы эш түгел.
2. Иртән зарядка **ясасаң** сәламәтлек өчен файдалы.
3. Эссе көндә салкын су **эчсәң** рәхәт, ләкин ярамый.
4. Укырга **теләсәң**, мин бу журналны синә берничә көнгә биреп торам.

Как скажете о том, что:

- Если бы ты делал рекламу, то какие цвета ты бы взял ?
- Если бы у меня были деньги,

я бы путешествовал по всему миру.

- Если будешь трудолюбивым,

многого добьешься.

Укучылар, онытмагыз: билгеле бер шартлар үтәлсә генә, тормышыбыз матур, киләчәгебез якты булыр.

Шарт фигыль шуңа өйрәтә.